**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча совет составына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча совет төзү турында» 2013 елның 30 гыйнварындагы ПУ-71 номерлы Указы (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 9 октябрендәге ПУ-1007 номерлы, 2014 елның 1 ноябрендәге ПУ-1015 номерлы, 2015 елның 14 ноябрендәге ПУ-1098 номерлы, 2016 елның 7 маендагы ПУ-405 номерлы, 2017 елның 17 апрелендәге ПУ-310 номерлы, 2018 елның 13 апрелендәге ПУ-308 номерлы һәм 2018 елның 6 июлендәге ПУ-473 номерлы, 2019 елның 19 мартындагы ПУ-174 номерлы, 2020 елның 17 апрелендәге ПУ-236 номерлы, 2020 елның 5 ноябрендәге ПУ-727 номерлы, 2021 елның 16 февралендәге ПУ-147 номерлы, 2022 елның 6 октябрендәге ПУ-715 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 6 апрелендәге 213 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча совет (алга таба – Совет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Совет составыннан М.Х. Сәлаховны, О.А. Третьяковны, А.В. Хохоринны, К.Г. Яковлевны чыгарырга;

б) Совет составына түбәндәгеләрне кертергә:

Вәлиуллин Ренат Нәкыйф улын – «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы Советы Башкарма комитеты җитәкчесе, «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы Советы рәисе урынбасарын (килешү буенча);

Кукушкина Наталья Владимировнаны – «Татарстан Республикасының мари милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисен (килешү буенча);

Миңнеханов Рифкать Нургали улын – «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесе президентын (килешү буенча);

Садретдинов Дамир Рөстәм улын – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрын (килешү буенча);

Титова Татьяна Алексеевнаны – «Россия антропологлары һәм этнологлары ассоциациясе» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлекчәсе рәисен (килешү буенча);

в) Совет әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Т.Р. Кадыйровның – «Татарстанның Халыклар дуслыгы йорты» дәүләт бюджет учреждениесе директоры (килешү буенча)»;

В.Е. Козловның – «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе Халыкара мөнәсәбәтләр институтының Татарстан тарихы, археология һәм этнология кафедрасы доценты (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2024 ел, 27 апрель
№ 306